Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы
КАРАРЫ

№ 30 11 июн 2021 ел

Түбән Мактама бистә Советының 2012 елның 27 декабрендәге 119 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Әлмәт районы муниципаль берәмлекләренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү комиссиясе тәкъдиме, Түбән Мактама бистә Советының 2008 елның 1 декабрендәге 93/1 номерлы карары белән расланган «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмә, Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге башлыгының «Гавами тыңлаулар билгеләү турында» 2020 елның 07 декабрендәге 10 номерлы карары нигезендә

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Түбән Мактама бистә Советының 2012 елның 27 декабрендәге 119 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы карарының махсус билгеләнештәге яшелләндерүнең территориаль зонасын (СН-3) киметү һәм IV класслы куркыныч производство-коммуналь объектларының (П4) территориаль зонасында шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына түбәндәге кадастор номерлы җир кишәрлекләренә карата үзгәрешләр кертергә: 16:45:070101:1440, 5000 кв.м мәйданлы җирләр; 16:45:070101:1652, 9320 кв.м. мәйданлы җирләр; 16:45:070101:1653, 5000 кв.м. мәйданлы җирләр (элегрәк 16:45:070101:1441, мәйданы 14320 кв.м.): Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә, Совет ур., 2Г йорт адресы буенча урнашкан.

2. Әлеге карарны Түбән Мактама бистәсе һәм Тихоновка авылы территорияләрендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), шулай ук Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә Башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов